ГЛАВА МАЙДАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МӘЙДАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

27.04.2018 _ с. Майдан № 2 _

Җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлауларны билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Мәйдан авыл җирлеге Уставы нигезендә,

Карар бирәм:

1. Кадастр номеры 16:15:100101:496 гомуми мәйданы 310 кв. м. булган җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү мәсьәләсе буенча халык алдында тыңлаулар уздырырга.

2. Мәйдан КФҮ түбәндәге адрес буенча ачык тыңлаулар үткәрү урынын билгеләргә: Мәйдан авылы, Совет урамы, 55 нче йорт. Үткәрү көне - 2018 елның 8 мае, үткәрү вакыты - 10.00.

Кадастр номеры 16:15:100101:496, гомуми мәйданы 310 кв.м. булган җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү мәсьәләсе буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр гавами тыңлауларда түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Мәйдан ав., Совет ур., 18 й.

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Югары Ослан муниципаль районы
Мәйдан авыл җирлеге башлыгы В. В. Михеев